



Бvген экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау актуаль. Мордовия Главасы Владимир Волков Гомумроссия халык фронты региональ бvлеге тәгъдимен - апрель аенда республикабызда экологик декада vткәрvне яклады. Гомумроссия халык фронты Мордовия халкын тирә-якны жыештыру субботникларында катнашырга чакыра. Наталья Алексеевна Сайгачева, Мордовия буенча РНК ОНФ бvлек житәкчесе, Дмитрий Александрович Массеров, «Генераль жыештыру» проекты житәкчесе журналистлар белән 20 апрельдә очрашты.       - Омәләр кон саен дәвам итәчәк. Мордовия санитар-экологик декада кысаларында, урамнарны һәм урманнарны тәртипкә кертv, чистарту буенча эш алып барылыр. Максаты – регионыбыз халкын яшәгән тирә-ягын кvләмле жыештыруга эндәv, урманнарны чvпләv фактларын фаш итv, хокук бозучыларны ачыклау, экологик ситуацияне яхшырту һәм экологик культура vстерv. Халыкка анлату эшләре vткәрv. Урманны саклау, чvп ташлау тыелу турында аншлаглар куела, корыган агачлар киселә, конкvреш һәм тозелеш чvп-чары жыештырыла. «Гел чvпләнә торган урыннарны беләбез, мониторинг алып барабыз, шул урыннарга график буенча гел йорибез», - диде Наталья Алексеевна. Үткән 2017нче елны шундый чараларда утыз меннән артык кеше катнашты. Катнашучылар белән тирә-якнын экологик торышын пычраткан 400 законсыз чvп свалкасы юк ителде, ди. Мисал иттереп vткән елгы фактларны мисалга китереп сойләде.
- Проект кысаларында ачык сетевой ресурс «Интерактивная карта свалок» (www/kartasvalok.ru) эшли. Анда кешеләр vзләре легаль булмаган чvп оемнәре яки свалка урыннарын билгели алалар. Картада барлыкка килгән урынга коммуналь хезмәт вәкилләре, ОНФ волонтерлары законсыз ташландыклар оемнәрен ачыклау һәм торле чаралар кvрv максатын кvздә тотып баралар,- ди Дмитрий Александрович Массеров. Ул МГУ студентларынын да бу эштә катнашулары турында әйтте.

**Наилә Насырова**